мәдәният. – 2003. – №4. – Б. 41–46.
2. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксис һәм пунктуациясе. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1984. – 258 б.
3. Мифтахов Б.М. Татар теле. 6 кл. өчен дәреслек. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981. – 136 б.
4. Мифтахов Б.М. Татар теле синтаксисын укыту методикасы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1968. – 136 б.
5. Сайкин Ш. Синтаксик төзелмәләрнең аерымлануы, аның кыен очраклары. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1980. – 160 б.
6. Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы: Морфология һәм синтаксис. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1959. – 642 б.

**Гарипова Айзирә Шамил кызы,**

**Устимова Гөлчәчәк Шамил кызы,**

**Абдуллина Гөлнара Вәзир кызы,**

*МАББУ «17нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*
*Әлмәт шәһәре, Татарстан, Россия*
*e-mail: 9172902183@mail.ru, aisira.79@mail.ru*
*aisira.79@mail.ru, ustimova_1971@mail.ru*

УДК 81.373

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КУШЫМЧАЛАР ЯРДӘМЕНДӘ ИСЕМ ҺӘМ СЫЙФАТ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕННӘН БУЛГАН ТЕРМИННАР ЯСАЛЫШЫ

# ОБРАЗОВАНИЕ ТЕРМИНОВ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

# FORMATION OF TERMS IN TATAR LANGUAGE

**Аннотация.** В последние два десятка лет происходит интенсивный рост количества новых татарских терминов и понятий, используемых в различных областях. Это вполне объяснимое явление, связанное с преподаванием предметов на татарском языке, с активной издательской деятельностью, ведением делопроизводства, Интернет- сайтов на татарском языке и, что особенно важно, принятием Закона РТ «О языках народов РТ», согласно которому татарский язык является одним из государственных языков в Республике Татарстан.

**Ключевые слова:** терминология,тюркология, грамматика.

**Abstract.**For the last two decades the intensive growth of the number of new Tatar terms and definitions has been happening, being used in the various fields.This is understandable phenomenon associated with teaching subjects on Tatar language, with an active publishing, records management, Internet sites on the Tatar language, and most importantly is the adoption Law of the Tatarstan Republic "About languages of the Tatarstan Republic", according to which the Tatar language is the one of the official languages of the Tatarstan Republic.

**Keywords:** terminology, turkology, grammar.

Татар әдәби теленең бай тарихы булган, заманында кызу бәхәсләр кузгаткан, төрле агымнар арасында үзенчәлекле көрәш тудырган, кызыклы һәм катлаулы проблемаларның берсе – терминология. Билгеле ки, телебездә атамалар төзү революциягә кадәр үк яктыртыла килгән, тик алар һәркайсы үз чорының берәр яклы карашын, вакыт-вакыт сыйнфый яки субъектив тарафчылык йогынтысын чагылдырганнар. 1930-1940 нчы елларда теориягә караганда практикачылык өстенлек итә. 1950-1960 нчы елларда фәнни теория һәм методлар нигезендә тикшерү шартлары туган. Әлбәттә, терминология мәсьәләсе фән-техниканың эше генә түгел. Ул мәктәп эшчәнлеге белән дә турыдан-туры бәйләнгән. Шуңа күрә бүгенге көндә дә терминнар киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә.

Сүзьясалыш ысуллары

Сүзьясалыш ысулы – нинди дә булса телнең материаль берәмлекләреннән, алар арасында сүзьясалыш мөнәсәбәтләре хасил итеп, яңа сүзләр ясау алымы, методы. Татар тел белемендә сүзьясалыш хакында бик үк

төгәл булмаган фикерләр яшәп килә. Тюркологиядә барлык грамматикаларда диярлек сүзьясалышның 3-4 ысулы гына бирелә. Ф. Ганиев үзенең хезмәтендә (2000, 45-88 б.) аның 8 ысулын китергән:

1. Фонетик.
2. Лексик-семантик.
3. Лексик-грамматик (конверсия).
4. Кушымчалау.
5. Сүзләр кушылу.
6. Сүзтезмәнең кушма сүзгә күчүе.
7. Сүзтезмәнең кушымча алып кушма сүзгә күчүе.
8. Кыскартылмалар ясалышы (аббревиация).

Кушымчалау, сүзләр кушылу, сүзтезмәләрнең кушма сүзгә күчү ысуллары иң продуктив ысуллар булып тора. Конверсия һәм лексик-семантик ысуллар ул кадәр үк продуктив түгелләр.

Кушымчалар ярдәмендә исем сүз төркеменнән булган терминнар ясалышы

Сүзьясалышының бу ысулы аның типларына яраклы рәвештә кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясаудан гыйбарәт.

Каюм Насыйри кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышына нык игътибар итә. Аның фикеренчә, татар телендә исемнәрдән һәм фигыльләрдән исемнәр ясаучы 19 кушымча бар (1985, 86 б.).

1960 нчы елларда В.Н. Хангилдин (1959) һәм Д.Г. Тумашева (1964) грамматикалары дөнья күрә. В.Н. Хангилдин исем ясаучы – 28, Д.Г. Тумашева – 19 кушымча китерәләр. Әмма бу хезмәтләрдә кушымчаларның тулысынча мәгънәләре ачылмый. Ф.С. Фасиев терминологиягә бәйләп сүз ясагыч кушымчаларын шактый җентекле тикшерә.

Хәзерге татар телендә исемнәр ясалышында кушымчалау ысулы продуктив һәм зур урын алып тора. Исем ясаучы кушымчалар күп төрле. Шуларның 30ы белән исем сүз төркеменнән булган терминнар ясалган. Иң продуктивлары –у/-ү, -лык/-лек, -лар/-ләр кушымчалары.

НИГЕЗ + -лык/-лек кушымчасы.

Татар теленең термин ясалышында иң продуктив кушымчаларның берсе.

Алмаш+лык – местоимение.

Аваздаш+лык – омонимичность.

Терминның нигезе алынма мүз булуына карамастан, атаманы ясау ысулы татар теленең үзенеке булганга күрә, безнең ана телебездә ясалган дип әйтергә хокукыбыз бар.

Бер+лек – единственное число.

Дөгече+лек – рисоводство.

Ясаучы нигезләрнең структурасы ягыннан караганда, алар тамыр да һәм, безнең мисалыбыздагыча, кушымчалар да булырга мөмкин.

Киң+лек – широта.

Кошчы+лык – птицеводство.

Иңкү+лек – низменность.

НИГЕЗ + -чык/-чек кушымчасы

Ясаучы нигезләрнең барысы да татар сүзләре һәм кушымчалар нигезләргә сингармонизм законнарына буйсынып ялганалар.

Бөре+чек – маленькая почка.

Таяк+чык – тычинка.

Култык+чык – заливчик.

НИГЕЗ + -чы/-че кушымчасы

Ефәк+че – шелкопряд.

Ияртү+че – подчиняющий.

Кош+чы – птицевод.

НИГЕЗ + -дык/-дек (-тык/-тек) кушымчасы

Буын+тык – сустав.

Муен+тык – шейка.

НИГЕЗ + -гыч/-геч (-кыч/-кеч) кушымчасы

Безнең мисалларда әлеге кушымча бары саф татар сүзләренә генә ялганып килгән.

Бөрке+геч – опрыскиватель.

Киптер+геч – сушилка.

НИГЕЗ + -ча/-чә кушымчасы

Кушым+ча – окончание.

Кызыл+ча – скарлатина.

Кабак+ча – кабачок

НИГЕЗ + -ыш/-еш,-ш кушымчасы

Лексик-семантик һәм морфологик билгеләреннән чыгып караганда, -ыш кушымчасы , эш-хәрәкәт атамасын белдергәндә эш сүзенә барып тоташа. Ясаучы нигезләре булып бары фигыльләр генә килә.

Сул+ыш – дыхание.

Юнәл+еш – залог.

НИГЕЗ + -ык/-ек, -к кушымчасы

Чыганак тел ягыннан ясаучы нигезләре булып бары татар сүзләре генә килә.

Сыз+ык – тире.

Ян+ык – огнище.

НИГЕЗ + -у/-ү, -ау/әү кушымчасы

Агула+у – протравливать.

Калькалаш+у – калькирование.

НИГЕЗ + -лар/-ләр кушымчасы

Күплекне белдерә торган грамматик флрмант гына түгел, ә сүзьясагыч чара буларак та килергә мөмкин.

Башаклы+лар – зерновые

Имезүче+ләр – млекопитающие

НИГЕЗ +-лы/-ле кушымчасы

Ревматизм+лы – больной реввматизмом.

Лишай+лы – страдающий лишаем.

НИГЕЗ + -чалар/-чәләр кушымчасы

Бу кушымча ярдәмендә ботаника өлкәсенә караган атамалар ясалган. Термин ясауның әлеге моделе ясаучы нигез белән бәйле үсемлекләр гаиләлеген белдерә:

Роза+чалар – розоцветные.

Үрдәк+чәләр – утиные.

НИГЕЗ + -ым/-ем,-м кушмчасы

Әлеге модель терминнар ясаганда ясаучы нигез булып фигыльләр килә.

Бет+ем – окончание.

Ер+ым – овраг.

НИГЕЗ + -ма/-мә кушымчасы

Кагыйдә буларак, әлеге кушымча фигыль нигезләргә ялгана. Сирәк очракларда гына исемнәргә ялганып килергә мөмкин.

Ишел+мә – обвал.

Казыл+ма – ископаемое.

НИГЕЗ + -чыл/-чел кушымчасы

Татар телендә бу кушымча белән ясалган терминнар күп түгел. Ул исемнәргә ялгана. Ясаучы нигезләре булып татар сүзләре килә.

Ут+чыл – огневка.

НИГЕЗ + -даш/-дәш (-таш/-тәш) кушымчасы

Зыян+даш – эпилепсия.

Имчәк+тәш – молочный брат, молочная сестра.

НИГЕЗ + -ган/-гән (-кан/-кән) кушымчасы

Кычыт+кан – крапива.

Сөтле+гән – молочай.

НИГЕЗ + -ыч/-еч, -ч кушымчасы

Кәрлә+ч – молодило.

Серкә+ч – тычинка.

НИГЕЗ + -ак/-әк, -к кушымчасы

Ерган+ак – рытвина.

Ерма+к – овраг.

НИГЕЗ + -ганак/-гәнәк кушымчасы

Сыр+ганак – облепиха һәм башкалар.

Кушымчалар ярдәмендә сыйфат сүз төркеменнән булган терминнар ясалышы

Татар телендә кушымчалар белән сыйфатлар ясалышы иң продуктив ысулларның берсе булып тора. Татар тел белемендә гомуми грамматикаларда кушымчалар белән сыйфатлар ясалышы китерелә. И.Гиганов, М.Иванов, Г.М. Мәхмүдов, Х. Фәйзханов, К.Насыйри, А.Архангельский грammтикаларында ук сыйфатлар ясый торган кушымчалар турында белешмә бар. Сыйфатлар ясый торган кушымчалар бик күп булсалар да, шуларның җидесе генә сыйфат сүз төркеменнән булган терминнар ясыйлар.

НИГЕЗ + -лы/-ле кушымчасы

Бу кушымча сыйфат сүз төркеменә кергән терминнарны иң күп ясаучы кушымчаларның берсе.

Басым+лы – ударный.
Бизгәк+ле – малярийный.
Саф татар сүзләре дә, алынма сүзләр дә ясаучы нигезләрне тәшкил итәргә мөмкин.
Ия+ле – личный.
Ияртү+ле – подчинительный.
Бу кушымча ясаучы нигез тамыр гына түгел, ә кушымчалыга да ялганып килә ала.
Кайтым+лы – возвратный.
Шунысы кызыклы, бу кушымча терминнар ясаганда бары тик исем сүз төркеменнән булган нигезләргә генә ялгана.
Тимгел+ле – сыпной.
Яңгыравык+лы – звонкий.

НИГЕЗ + -сыз/-сез кушымчасы

Бу кушымча татар телендә полифункциональ кушымча тәшкил итә. Ул, беренчедән, сүз ясагыч кушымча булып тора. Шуның белән бергә ул грамматик мөнәсәбәтне дә белдерергә мөмкин.
Ия+сез – безличный.
Кайтым+сыз – невозвратный.
Көчем+сез – непереходный.

НИГЕЗ + -гыч/-геч (-кыч/-кеч) кушымчасы

Ул, кагыйдә буларак, фигыльләргә ялгана. Ясаучы нигезләре булып тик татар сүзләре генә килә.
Төрләндер+геч – словоизменительный.
Сызгыр+гыч – свистящий.

НИГЕЗ + -ган/-гән (-кан/-кән) кушымчасы

Яхшыртыл+ган –селекционный.
Иренләш+кән – лабиализованный.

НИГЕЗ + -ма/-мә кушымчасы

Бу кушымча ярдәмендә ясалаган терминнарның ясаучы нигезләре булып бары фигыльләр генә килә.
Күчерел+мә – иносказательный.
Төш+мә – нисходящий.

НИГЕЗ + -чыл/-чел кушымчасы

Биз+чел – жилистый

Хәзерге татар әдәби теленең терминологие системасына күзәтү ясап, аның сүзьясалыш ысулларына, юлларына һәм чараларына турыдан-туры бәйләнгән булуын нигезләү максатыннан чыгып, үзлекләрдән мисаллар туплаганнан соң, без шундый нәтиҗәгә килдек: термин сүзләр белән гадәти сүзләр арасында кытай стенасы юк. Фәннәрнең өзлексез үсүе һәм нәтиҗәләрнең көнкүрешкә үтеп керүе сәбәпле, терминнарның төшенчәсе масса тарафыннан үзләштерелә һәм алар гади сүзгә әйләнәләр. Яңа терминнар туа, искеләрдән бер өлеше гадиләшә тора. Бу – иҗтимагый күренеш,  ул фән һәм тормышның бәйләнешен чагылдыра.

Шулай итеп, без татар теле белемендә сүзьясалышы һәм термин ясалышына караган хезмәтләрне өйрәнеп, сүзлекләргә таянып, татар теленең үз ысуллары белән ясалган терминнарына синхроник тасвирлама бирдек.

Вакытлар үтү белән, тел составы үзгәрә, яңа сүзләр һәм терминнар белән байый, алар төрле чаралар белән телнең үз сүзләреннән ясала, башка телләрдән керә, искергән сүзләр төшеп кала, я кире кайта, ягъни тел һәрвакытта хәрәкәттә. Шулай булгач, телдә тикшерү өчен яңадан-яңа темалар барлыкка килә.

**Әдәбият**

1. Әхмәтҗанов, Р. Әдәби-мәдәни сүзлек: Терминнар тарихыннан // Татарстан яшьләре. – 1986. – 13 ноябрь.
2. Әхмәтҗанов, Р. Татар терминологиясе тарихи чыганаклары // Фән һәм мәктәп. – 2000. – № 3. – Б. 3-13.
3. Борһанова, Н.Б. Үсемлек атамалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 585-611 б.
4. Ганиев, Ф.А. Суффиксальное словообразование в современном татарскм литературном языке . – Казань: Таткнигоиздат., 1974. – 231 с.